# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 15 ноябре №10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 2000,00 сум күләмендә кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 28 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 17 кеше кертелде, бу 60,7% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 17 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 2000,00 сум күләмендә кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру) мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлегенең Кызыл Кармыш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

4. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (инерт материаллар сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И. М. Фәтхуллин